ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 20.06.2024 866 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2024 елның 31 гыйнварындагы 130 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2024 елның 31 гыйнварындагы 130 номерлы карарына үзгәрешләр кертеп, 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү секторына әлеге схеманы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге сайтында урнаштыруны һәм әлеге карар раслаганнан соң биш көн эчендә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Алабугга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның___ _____ _____
номерлы карарына 2 нче кушымта

20.06.2024 866

Алабуга шәһәре территориясендә җир кишәрлекләре бирмичә генә
стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/н | Факттагы адресы | Стационар булмаган сәүдә объектларының саны (берәмлекләр) | Стационар булмаган сәүдә объектының тибы | Сатыла торган товарлар төре (ассортименты) | Объектны куллану |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Александровка бакчасы» паркы территориясендә | 3 | Лоток | Татлы мамык, попкорн, карамель алмалар, эчемлекләр, туңдырма | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |
| | | 3 | | Аттракционнар | |
| 2 | «Гуляй» паркы территориясе | 2 | Лоток | Татлы мамык, попкорн, карамель алмалар, эчемлекләр, туңдырма | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |
| | | 4 | | Аттракционнар | |
| 3 | «Пионерский» паркы территориясе | 2 | Лоток | Татлы мамык, попкорн, карамель алмалар, эчемлекләр, туңдырма | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |
| | | 2 | | Аттракционнар | |
| 4 | «Чебурашка» балалар мәйданчыгы территориясе | 2 | Лоток | Татлы мамык, попкорн, карамель | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | алмалар, эчемлекләр, туңдырма | |
| 5 | «Шишкин буалары» территориясе | 2 | Лоток | Татлы мамык, попкорн, карамель алмалар, эчемлекләр, туңдырма | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |
| 6 | «Георгиевский» паркы территориясе | 4 | Лоток | Татлы мамык, попкорн, карамель алмалар, эчемлекләр, туңдырма | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |
| | | 2 | | Аттракционнар | |
| 7 | Өй янындагы сквер территориясе | 6 | Лоток | Татлы мамык, попкорн, карамель алмалар, эчемлекләр, туңдырма, спорт батутлары, аттракционнар (машиналар, джамперлар) | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |
| 8 | Причал территориясе | 7 | лоток | Татлы мамык, попкорн, карамель алмалар, эчемлекләр, туңдырма | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, үзмәшгульләр |
| 9 | Чаңгы-роллер трассасы | 2 | киоск | Татлы мамык, попкорн, карамель алмалар, эчемлекләр, туңдырма | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |
| 10 | «Корица» кафесы территориясе яны, Казан урамы, 28а нче йорт | 1 | веранда | Җәмәгать туклануы | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 11 | «La vera pizza» кафесы территориясе яны, Набережная урамы, 10 нчы йорт | 1 | веранда | Җәмәгать туклануы | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |
| 12 | «Шайтан каласы» («Чёртово городище») территориясе яны | 1 | | | |
| 13 | Шәһәр пляжына якын территория | 4 | фуд-трак | Җәмәгать туклануы | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары |